Гайнуллина Г.Р.

# И.Әбүзәров прозасында мотифемалар

Рус телендә иҗат итүче Илдар Әбүзәров (1976) соңгы еллар прозасына әдәби образлар һәм детальләр белән төгәл һәм зәвыклы эш итүе белән танылып, кыю үтеп керә. Аның тәүге “Корбан-роман” (2009 елда бас.) дип исемләнгән китабына киң катлам укучы яратып өлгергән “Корбан-роман”, “Почта”, “Мавр” һ.б. хикәяләре кертелә.

Безнең максат – авторның “Корбан-роман” (бер корбан тарихы) һәм “Мавр”, “Яратмау”, Күңелем теләгәннәре” хикәяләрен өйрәнү объекты итеп алып, әдип прозасында мотифемаларның сюжет корылышында парадигмаль чылбыр хасил итүен күзәтү.

И.Әбүзәров текстларының сәнгатьчә бөтенлегенең интерсубъектив чынбарлык дәрәҗәсен анализлау барышында түбәндәге фикерләр билгеләп куелды.

Мәгълүм булганча, мифологик фикерләү белән сюжетны вертикаль һәм горизонталь вектор-юнәлешле булу аерып куя. Автор текстларының классик бөтенлеген сюжет корылышында инициация схемасына якын торган дүрт баскычлы динамик структураны куллану билгели. Инициациянең вакыйгалар схемасы белән сюжет схемасы арасындагы матрицаны – тышкы яктан бер-берсенә охшамаган сюжетларның дүрт фазадан гыйбарәт динамик структурасын И.В.Силантьев, В.И.Тюпа, И.В.Шатин билгеләп куялар. Фазаларның атамалары – аерылу, партнерлык, гөнаһ кылу, лиминаль, үз асылыңа кайту.

И.Әбүзәровның “Корбан-роман” хикәясе “корбан” мифологик мотивын уйнату ярдәмендә авторның яшәеш хакындагы уйлануларын “чишү” кебек укыла. Текстның беренче өлеше “корбан китерү” вакыйгасын сөйләү икенче – корбанчыллык, хәтер мотивларын алга куеп сөйләнгән вакыйганы шәрехләргә ярдәм итә.

Аерылу – үз асылыңнан китү мотивын “сирәк очрый торган талантлар” Стасик, Витек, Белосток филармониясенең солистлары Юныс (яки Юся),

хикәяләүче  һәм ноталар һәм грампластинкалар белән сату итүче эшкуар Венцеслав Бохоник янындагы фермага Корбан гаете алдыннан сыер алырга килү вакыйгасы әзерли. Хикәяләү сыер сую вакыйгасын җентекләп тасвирлау белән дәвам итә. “Колаклары ак, аяклары ак, күзләре чем-кара” сыерны музыкантларга пан Тадеуш үзе сайлап бирә. Үлемнән котылырга ашкынган сыер сурәте дә текстның икенче өлешен “уку” өчен кирәк: Маруся кушаматлы корбан текстның икенче өлешендәге сөйгәнен савыктыру өчен эфтаназия – корбанга барган Марыся исемле кыз вакыйгасын укырга ярдәм итә.

Музыкантларның сыер сую вакыйгасын күзәтүләре – аерылу мотивының редукцияләнгән варианты. *“Закрыв глаза, прислушиваясь только к протяжному пению ветра, я снял перчатки и положил руку на огромную, теплую шею коровы, другой рукой поднося к теплу ее жизни лед тесака” / “Күзләремне йомдым да  бары тик җилнең озын көен тыңлый-тыңлый, перчаткаларымны салдым һәм бер кулымны сыерның киң, җылы муенына куйдым, икенче кулым белән аның гомеренең шушы җылысына пычак бозын китердем”* [1:22]

Партнерлык мотивы гөнаһ кылу мотивы белән кушылып китә. Вакыйгалар барган икенче урын буларак Белостоктагы “Музыкальное кафе” сайлана. Яшәешне аңлауга Паганини каприслары ярдәм итә, хикәя структурасында бу деталь кабатлана. Сөйгәне хыянәтен кичерүдән авыруга сабышкан прима-балерина Марыся “Жизель” балетын модернизацияләргә кирәк, дип уйлый: текст Жизельның яраткан кыңгырауларын җыюдан башлансын, соңыннан шул кыңгырауларныны Альберт аның каберенә китерсен, дип үз язмышын укучыдан укыта. Марысяның сагышы  Перселлның “When I am iaid in earth”ы һәм Вердиның “Pace, mio dio”сы белән чагыштырыла. Сыер чалу белән бәйле кичерешләр тасвиры  – кызыл шәраб – кан кебек, агы сөткә охшаган булуы Беллининың “Mira o Norma”сы аша аңлатыла. Геройлар “Bella figlia dell amore”,  “Donna non vidi mai”, “Небесная Аида” ария һәм дуэтларын тыңлап,

лимонад кушылган җиңелчә сыра уртлый-уртлый бефстроганннар ашый-ашый, минерал су кушылган ак шәраб эчкәндә, “Мадам Баттерфляй”дан “Vogliatemi bene”, “Мадам Бовари”, “Мадам Клико”, “Гастон Шарпантье Шато Брюне Сент-Эскаль”ның мәхәббәт дуэтлары укучыга ишеттерелә кебек. Аллаһның рәхмәтенә өмет итү – Вердиның “Pace, mio dio” юллары, дип фикерләр башка сәнгать теленә күчерелеп, яшерелеп, уен төсендә тәкъдим ителә. Сәнгать текстлары белән таныш булмау “киң пландагы авторны” төгәл аңлаудан ерагайта.

Археосюжетның өченче – лиминаль фазасы – үлем белән сынау вакыйгалар катламында Стася-Витуся-Марыся мәхәббәте өчпочмагы мотивы белән кушылп сөйләнелә. Автомобиль астында калган Стасяны коткару өчен аны яраткан кызларның тән әгъзаләре алыну, сөйгәнен коткару өчен корбан булган Марыся турында уйланулар әсәрнең фәлсәфи нигезен тотып тора. Хәтер мотивы корбан мотивы белән шул рәвешле янәшә куела: *“Ну как вы думаете, что более жертвенно: умереть во имя любимой, зная, что она тут же забудет о вас и никогда не вспомнит. Не вспомнит даже вашего имени и лица, не говоря уже о вашем жертвенном поступке. Или принести себя в жертву, спасая человека, в которого по уши влюблена ваша ненаглядная. Иначе говоря, спасти собственного соперника ценой собственного счастья. Или несчастья – кому как больше нравится”.* (*тәрҗемә Л.Әбударовanыкы*) [1:35-36]

Дүртенче үз асылыңа кайту, үзгәрү, яңару фазасы инициация схемасының соңгы баскычына охшаш. Геройның статусы, бу очракта психологик, эчке халәте үзгәрә: текстның ахырында асылын аңламыйча чалынган корбанга караганда хәтер мөһимрәк, дигән нәтиҗә ясала: *“А еще я верил, что в конечном итоге мы оказались счастливее Стасика, потому что ... он не помнил их жертвенной любви. А мы помнили”.*

“Мавр” хикәясе кешенең юл сайлау мөмкинлеге турында. Биредә дин фәлсәфәсен Коръәнгә нигезләнеп аңлату үзәккә алына. Мавр образы

ярдәмендә кешенең үз хисләренә хуҗа була алу, түбән хислрдән саклану турындагы фикерләр җиткерелә. Аерылу мотивы белән партнерлык мотивы – җиңел табышка кызыккан “Юнга” кушаматлы егет Маврны үзе эшли торган түбән урында да, кинозалда да күрү вакыйгасында . Университет профессоры бик абруйлы кеше булып чыга. Логистикадан зачетны бирү өчен “койрыклы” студент аның янына махсус килергә мәҗбүр була. Профессор студентка соңгы шанс бирә, ләкин эшендәге уңайсызлыклар аркасында студент тиешле вакытка килеп җитә алмый, нәтиҗәдә, студент профессорның өенә бара. Мавр ярдәмендә текстта уенда җиңелгән кеше үләргә тиеш дигән эчтәлектә лиминаль фаза билгеләнә. Маврның йорт сурәте, үзен тотышы, егетне акылга утыртуы Ислам фәлсәфәсен аңлату белән бәйле алып барыла. Студент алдан укып килергә тиешле китап Коръәндәге юл сайлау мотивын кабатлый. Автор Мавр теле белән, тормышта сайлау мөмкинлеге бар, ләкин аз икәнлекне әйтә: *“Вся наша жизнь – сон, выбор из двух зол или двух радостей, разве нет? А реальность наступит после пробуждения…Выбирайте меньшее зло ли то, что вам доставит большую радость*” [2:269]. Юл сайлау җаваплылык, гамьлелек сорый, һәр гамәлнең нәтиҗәсен алдан күрә алу белән бәйле әзерлек таләп итә: *“Вы решили обмануть судьбу и выбрали наиболее дерзкий способ. Вы догадались, что выигрыши, выпадающие в автоматах, не случайны. Что они заложены в программу, тогда вы решили, что их можно предугадать, т.е.заглянуть в книгу судьбы... Плохо в вашем поступке то, мой друг, что вы не покорились своей судьбе, а с помощью тайных знаний попытались изменить ее. Гордыня, мой друг - страшный грех... И вообще, вступив на дорогу порока, так трудно последовать учению Пророка. Вас будто блокирует раз выбранный путь, не давая шанса переиграть жизнь”*. [2:270].

Ахырда студент егетнең бу төше аны үзгәрүгә, җаваплырак булырга этәргән вакыйга икәнлеге аңлашыла.

“Яратмау турында” хикәясе геройның азгын кызның үлеме турында ишетүе белән башланып китә. Кызны яратмаса да, наз иркенә бирелүен герой

ярату хисеннән китүенең сәбәбе дип күрә, фәхишә кыз, аның үткәннәре турында турында уйланулары егетне рухи үлемгә китереп җиткерә, лиминаль мотив урнаша. Караңгы хисләр чоңгылыннан чыга алмаган герой укучыны уйландырыр дип көтелә. Әйтергә кирәк, әлеге хикәяне укыганда И.Әбүзәров яңа реализмның Кельн мәктәбе традицияләре белән таныш, дигән тойгы кала.

Археосюжет мотифемаларның парадигмаль чылбыры авторның башка текстларында да урын ала. Моңа “Күңелем теләгәннәре” хикәясендә девочка Ляйне эшләнешен мисал итеп китереп була. Кулына нарат күркәсе тоткан тиен белән чагыштырылган кыз Арвены яңа хисләр чынбарлыгына алып чыга. Кызның гап-гади чынбарлыкны сихри итә белүе белән юанып яшәүче Арве Ляйненың алдавына гарьләнә, лиминаль мотив сюжетны төгәлли, укучы җаваплылык турындагы чишелешне үзе уйлап бетерә.

Автор дискурсының археосюжет мотивлар комплексына нигезләнүе аның әдәби текстларының бөтенлеген билгели.

Кулланылган әдәбият исемлеге


1. Абузяров И.А. Курбан-роман. – М.: Центр книги ВГБИЛ им. М.И.Рудомино, 2009. – С.14-51.
2. Абузяров И.А. Мавр. – М.: Центр книги ВГБИЛ им. М.И.Рудомино, 2009. – С.235-271.
3. Абузяров И.А. О нелюбви. – М.: Центр книги ВГБИЛ им. М.И.Рудомино, 2009. – С.195-238.
4. Саморукова И.В. Художественное высказывание как эстетическая деятельность: типология и структура креативного опыта в системе дискурсов. Автореф.дисс. докт. филол.н.– Екатеинбург, 2004. 43 с.
5. Силантьев И.В. Сюжетологические исследования. – М.: Языки славянской культуры, 2009. – 224 с.